Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
СОВЕТЫ

# К А Р А Р

2020 елның 25 марты № 44/2

Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибе һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча 2020 нче елның 3 февралендәге Бәяләмәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2018 елның 16 августындагы 28/5 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибе һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәгә, 3.21 пунктын түбәндәге яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.21. Комиссия тарафыннан административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре булган гамәлләр (гамәл кылмау) факты ачыкланган очракта, комиссия рәисе мондый фактны административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында, административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексында һәм Россия Федерациясе Җинаять кодексында, хокук куллану органнарына өч көн эчендә, шулай ук кылына торган җинаятьне яки административ хокук бозуны булдырмый калу, дәлилләрне фиксацияләү, җаваплылыкка тартуның күптәнге вакытын чикләү максатларында – кичекмәстән хәбәр бирергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чүпрәле муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А.М. Хасановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров